**КАРАР**

**Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбья авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**19 ноябрь, 2021 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 19 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбья авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 2100 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Яңа Чәбия авылы территориясен төзекләндерү (җәйге чорда территорияне чабу, өрәңге агачларын кисү, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, хуҗасыз ташландык йортларны җимерү, территорияне чүп-чардан арындыру);
- Яңа Чәбия авылы зираты коймаларын буяу һәм ремонтлау (чыгым материалларын сатып алу һәм ташу, килешү һәм техник күзәтчелек буенча эшләр өчен түләү);
- Су белән тәэмин итү ситсемасын төзекләндерү (су торбалары сатып алу һәм урнаштыру, су зонасы коймаларын ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү, материал сатып алу);
- Кыш көне Яңа Чабия авылы юлларын кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 38 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 23 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 23 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбья авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: ««Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбья авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 2100 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Яңа Чәбия авылы территориясен төзекләндерү (җәйге чорда территорияне чабу, өрәңге агачларын кисү, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, хуҗасыз ташландык йортларны җимерү, территорияне чүп-чардан арындыру);
- Яңа Чәбия авылы зираты коймаларын буяу һәм ремонтлау (чыгым материалларын сатып алу һәм ташу, килешү һәм техник күзәтчелек буенча эшләр өчен түләү);
- Су белән тәэмин итү ситсемасын төзекләндерү (су торбалары сатып алу һәм урнаштыру, су зонасы коймаларын ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү, материал сатып алу);
- Кыш көне Яңа Чабия авылы юлларын кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

2. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Нырты авыл җирлеге башлыгы: Т. А. Котдусов

ОГРН 1061675011243
ИНН 1623008592